ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис, Верхнеуслонский район, Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 03.09.2018 г. Иннополис № 54 КАРАР

«Тышкы мәгълүмат чараларын (паспорт) урнаштыру проектын килештерү буенча Иннополис шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 21 мартындагы 14 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законга гариза бирүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән бирнечә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәкләрендә күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 479-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Иннополис шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан тышкы мәгълүмат чараларын (паспорт) урнаштыру проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2013 елның 21 мартындагы 14 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә, 1 нче кушымта нигезендә

2. Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортны) килештерү буенча Иннополис шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты статьяларының яңа редакциясен расларга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет - телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) Иннополис шәһәре Мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р. Р. Шагалиев

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының "____" ________2018 ел, №____ карарына

Кушымта

Тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын (паспортны) килештерү буенча Иннополис шәһәре башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына өстәмәләр һәм үзгәрешләр.

1. Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 21 мартындагы 14 номерлы карары белән расланган Тышкы мәгълүмат чараларын (паспорт) урнаштыру проектын килештереп, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә (алга таба - административ регламент).

1.1. Административ регламентның 5.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктчалар өстәргә:

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яисә тәртибен бозу»

«9) туктатып тору нигезләре федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору. Күрсәтелгән очракта күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судтан тыш) шикаять бирү күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерүе «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәтләрне күрсәтү функциясе йөкләнгән булса мөмкин.

1.2. Административ регламентның 5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан йә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъва, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, “Интернет” мәгълүмат-

телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр төбәк порталыннан файдаланып почта аша юлланырга мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Әлеге Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.»

1.3. Административ регламентның 5.9 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә түләтү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә канәгатьләндерелә.»

Иннополис шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе Р. Р. Шагалиев